Ак күгәрченнәр көне : [Бөек Җиңү көне уңаеннан 8 нче санлы китапханә хезмәткәрләре һәм актив «Җиңү волонтерлары» 21 нче мәктәп укучылары өчен мастер-класс үткәрде] // Көмеш кыңгырау. – 2026. – № 17 (7 май). – Б. 2.

**Бөек Җиңү көне уңаеннан 8нче санлы китапханә хезмәткәрләре һәм актив «Җиңү волонтерлары» 21нче мәктәп укучылары өчен «Ак күгәрчен – тынычлык һәм дуслык символы» дигән мастер-класс үткәрде.**



# Ак күгәрченнәр көне

«Җиңү волонтерлары» чарада катнашып кына калмады, оештыруда да чын ярдәмчеләр булды. Алар материаллар әзерләүдә актив булышты, катлаулы урыннарын аңлатты һәм уңай атмосфера тудырды.

Китапханәчеләр күгәрченнәрнең сугыш елларындагы роленә аерым тукталды. Балалар аларның хат ташучы кошлар буларак кулланылуын, камалышта калган гарнизоннар өчен күгәрченнәрнең бердәнбер элемтә чарасы һәм ярдәм сорау мөмкинлеге булуын белделәр.

Очрашу ахырында һәр бала катыргыдан һәм салфеткалардан үз куллары белән тынычлык һәм игелек символы саналган ак күгәрчен ясады.

